**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 7 октябрь № 720

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халык сәнгать һөнәрләре тармагында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 25 май, 368 нче карары белән расланган Халык сәнгать һөнәрләре тармагында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халык сәнгать һөнәрләре тармагында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 25 май, 368 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 15 июль, 516 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Халык сәнгать һөнәрләре тармагында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлекнең 1.5 пунктына «тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән күрсәтелгән максатларга каралган бюджет ассигнованиеләре күләме кысаларында» сүзләрен өстәргә;

2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле пункт өстәргә:

«2.2. Субсидия түбәндәге шартларга җавап бирә торган эшмәкәрлек субъектларына бирелә:

үзгәртеп төзү, бетү яки банкротлык стадияләрендә булмаган;

элек бирелгән бюджет чараларын максатсыз һәм (яки) нәтиҗәсез файдалануны булдырмаган;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына һәм дәүләт бюджеттан тыш фондларына мәҗбүри түләүләр буенча кредит бурычлары булмаган.»;

6.2 пунктта:

«е» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«е) грантның хисап финанс елында файдаланылмаган өлешен агымдагы финанс елында кире кайтару очраклары;»;

түбәндәге эчтәлекле «и» пунктчасын өстәргә:

«и) алынган акча исәбеннән чит ил валютасын сатып алу тыела, югары технологияле чит ил җиһазларын, чималны һәм комплектлау эшләнмәләрен сатып алганда (керткәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш.»;

7 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## «7. Грантларны файдалануны тикшерүдә тоту һәм аларны кире кайтару тәртибе

7.1. Грант алучы грант бирү турында килешүдә билгеләнгән вакыт эчендә Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына әлеге Тәртипкә 6 нчы кушымтага ярашлы форма буенча ике нөсхәдә грантны максатчан файдалану һәм проектны тормышка ашыру турында хисап  һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы Халык сәнгать һөнәрләре буенча сәнгать-эксперт советының эшләнмәләрне халык сәнгать һөнәрләре эшләнмәләренә керүен раслый торган бәяләмәсен тапшыра.

7.2. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының тиешле таләбен алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә грантлар түбәндәге очракларда Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш:

грант бирү шартларын үтәмәгән;

грантлары максатчан файдаланмаган;

грант алучы грантны максатчан файдалану һәм проектны тормышка ашыру турында хисап бирмәгән.

7.3. Грантның хисап финанс елында файдаланылмаган өлеше грант бирү турында килешүдә каралган очракларда хисап елыннан соң килүче айның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш.

7.4. Грант алучы әлеге Тәртипнең 7.2 һәм 7.3 пунктларында билгеләнгән грантны кире кайтару вакытларын бозганда Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы кире кайтару вакыты тәмамланган көннән соң календарь көннәрдә исәпләнгән 10 көн эчендә грантларны Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару чараларын күрә.

7.5. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы законнар нигезендә грантлар алучыларның грантлар бирү шарларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүне гамәлгә ашыра.

7.6. Грантны максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы законнар нигезендә гамәлгә ашыра.»;

әлеге Тәртипкә 1, 4, 5 нче кушымталарда «м.у.» сүзләреннән соң «(булганда)» сүзләрен өстәргә;

әлеге Тәртипкә  2, 3, 6 нчы кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2016\720.docx